**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.04.2018 № 291

2017 нче елның 13 ноябрендәге 1077 нче карарга
үзгәрешләр кертү турында

“Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 ел, 25 июнь, 52-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 13 ноябрендәге 1077 нче карары белән расланган Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь төзекләндерүнең Төбәк программасын үтәү буенча Кыска вакытлы планының 2017 ел өлешенә, яңа редакциядә раслап, үзгәрешләр кертергә (1 нче кушымта).

2. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.С. Әхмәтшин

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының

2018 ел, 18 апрель, 291 номерлы
карарына 1 нче кушымта

## Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь төзекләндерүның Озак вакытлы программасын үтәү буенча Кыска вакытлы планы

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 13 ноябрендәге 1077 нче карары белән расланган Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь төзекләндерүның Озак вакытлы программасын ( алга таба – Озак вакытлы программа) үтәү буенча бу Кыска вакытлы план (алга таба-Кыска вакытлы план) Россия Федерациясе Торак кодексы, "Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм итү фонды турында" 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль законы (алга таба – Федераль закон), «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - Татарстан Республикасы Законы) нигезендә, Төбәк программасын үтәү, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү срокларын төгәлләштерү, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча планлаштырыла торган хезмәт күрсәтүләр һәм эшләрне ачыклау, капиталь ремонт үткәрүдә дәүләт һәм муниципаль ярдәм күрсәтү төрләрен һәм күләмен билгеләү максатында эшләнде.

## II. Кыска вакытлы планның төп максатлары һәм бурычлары

Кыска вакытлы планның төп максатлары булып:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районындагы торак фондының сакланышын тәэмин итү, яңарту һәм сыйфатын яхшырту;

халыкка имин һәм кулай яшәү шартлары тудыру;

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүдә дәүләт һәм муниципаль ярдәм күрсәтү тора.

Кыска вакытлы планның төп бурычлары булып:

халык белән актив агитация-аңлату эшләре алып бару;

Программаны башкаручыларны сайлап алу процедураларын ачык һәм халыкка билгеле булырлык итеп үткәрү;

нәтиҗәле техник карарлар кабул итү һәм капиталь төзекләндерү барышында озакка чыдый торган материаллар, ресурсны саклый торган технологияләрнең комплекслы кулланылуына ирешү.

Әлеге Программа 2017-2019 елларда гамәлгә ашырыла.

Программаны тормышка ашыру:

- 2017 елда: 28,8 мең кв.метрлы 14 күпфатирлы торак йортта 1103 гражданның яшәү шартлары яхшыртырга тиеш;
- 2018 елда: 27,8 мең кв.метрлы 16 күпфатирлы торак йортта1024 гражданның;
- 2019 елда: 33,3 мең кв.метрлы 12 күпфатирлы торак йортта 1289 гражданның яшәү шартлары яхшыртырга тиеш.

III. 2017 елда күпфатирлы йортларда капиталь ремонт эшләренең күләме

| Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь төзекләндерү буенча хезмәтләр яки эшләрнең исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эшнең күләме |
|---|---|---|
| Түбәне төзекләндерү | мең кв.метр | 10, 344 |
| Йорт эчендәге инженерлык системаларын төзекләндерү | | 14,448 |
| Электр белән тәэмин итү | мең метр | 2,750 |
| Җылылык белән тәэмин итү | мең метр | 4,511 |
| Су белән тәэмин итү | мең метр | 3,772 |
| Суны агызып җибәрү | мең метр | 3,415 |
| Фасадларны җылыту һәм төзекләндерү | мең кв. метр | 15,582 |
| Күпфатирлы йортларда подъездларны төзекләндерү | мең кв.метр | 5,635 |

2018 елда күпфатирлы йортларда капиталь ремонт эшләренең күләме

| Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь төзекләндерү буенча хезмәтләр яки эшләрнең исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эшнең күләме |
|---|---|---|
| Түбәне төзекләндерү | мең кв.метр | 8,446 |
| Йорт эчендәге инженерлык системаларын төзекләндерү | | 17,097 |
| Электр белән тәэмин итү | мең метр | 2,856 |
| Җылылык белән тәэмин итү | мең метр | 6,441 |
| Су белән тәэмин итү | мең метр | 3,907 |
| Суны агызып җибәрү | мең метр | 3,893 |
| Фасадларны җылыту һәм төзекләндерү | мең кв. метр | 11,881 |
| Күпфатирлы йортларда подъездларны төзекләндерү | мең кв.метр | 5,211 |

I. 2019 елда күпфатирлы йортларда капиталь ремонт эшләренең күләме

| Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь төзекләндерү буенча хезмәтләр яки эшләрнең исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эшнең күләме |
|---|---|---|
| Түбәне төзекләндерү | мең кв.метр | 7,017 |
| Йорт эчендәге инженерлык системаларын төзекләндерү | | 20,871 |
| Электр белән тәэмин итү | мең метр | 3,025 |
| Җылылык белән тәэмин итү | мең метр | 7,939 |
| Су белән тәэмин итү | мең метр | 5,028 |
| Суны агызып җибәрү | мең метр | 4,879 |
| Фасадларны җылыту һәм төзекләндерү | мең кв. метр | 10,433 |
| Күпфатирлы йортларда подъездларны төзекләндерү | мең кв.метр | 2,579 |

Ресурслар белән тәэмин итү

Кыска вакытлы планның финанслау чыганаклары булып Фонд, Татарстан Республикасы һәм җирле бюджет чыганаклары, торак милекчеләре ширкәте әгъзалары, торак, торак-төзелеш кооперативлары (алга таба – ТМШ(ТСЖ), ТК (ЖК), ТТК (ЖСК)тиешле тәртиптә) яки махсус кулланучылар кооперативы йә күпфатирлы йортта торак хуҗалары кооперативы тора.

2017 елда Кыска вакытлы план чараларын финанслауның гомуми күләме:

Барлыгы - 45982026,57 сум, шул исәптән:

Фондтан- 0,00 сум;

Татарстан Республикасы бюджетыннан – 13 706 754,84 сум;

җирле бюджеттан – 11 288 000,00 сум;

ТМШ, ТК, ТТК әгъзалары яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы яки күпфатирлы йортта торак хуҗалары кооперативы – 209872271,73 сум.

2018 елда Кыска вакытлы план чараларын финанслауның гомуми күләме:

Барлыгы - 45982026,57 сум, шул исәптән:

Фондтан- 0,00 сум;

Татарстан Республикасы бюджетыннан – 12446168,00 сум;

җирле бюджеттан – 11 288 000,00 сум;

ТМШ, ТК, ТТК әгъзалары яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы яки күпфатирлы йортта торак хуҗалары кооперативы – 35200155,68 сум.

2019 елда Кыска вакытлы план чараларын финанслауның гомуми күләме:

Барлыгы - 57129865,75 сум, шул исәптән:

Фондтан- 0,00 сум;

Татарстан Республикасы бюджетыннан – 12202331,00 сум;

җирле бюджеттан – 11 288 000,00 сум;

ТМШ, ТК, ТТК әгъзалары яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы яки күпфатирлы йортта торак хуҗалары кооперативы – 33639534,75 сум.

2017 елда күпфатирлы йортларда капиталь ремонт эшләренең финанс чыганаклары ихтыяҗлары күләме

| Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь төзекләндерү буенча хезмәтләр яки эшләрнең исемлеге | Финанслау ихтыяҗы, сумнарда |
|---|---|
| Түбәне төзекләндерү | 19347611,01 |
| Йорт эчендәге инженерлык системаларын төзекләндерү,шул исәптән: | 16766217,25 |
| Электр белән тәэмин итү | 1565898,24 |
| Җылылык белән тәэмин итү | 9179765,88 |
| Су белән тәэмин итү | 1715891,99 |
| Суны агызып җибәрү | 4304661,14 |
| Фасадларны җылыту һәм төзекләндерү | 4499794,55 |
| Күпфатирлы йортларда подъездларны төзекләндерү | 3265367,44 |
| Проект документациясен эшләү һәм дәүләт экспертизасы үткәрү | 1349104,86 |
| Төзелеш контроле уздыру | 472426,30 |
| Техник паспортларны ясау | 281505,14 |
| БАРЛЫГЫ | 45982026,57 |

2018 елда күпфатирлы йортларда капиталь ремонт эшләренең финанс чыганаклары ихтыяҗлары күләме

| Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь төзекләндерү буенча хезмәтләр яки эшләрнең исемлеге | Финанслау ихтыяҗы, сумнарда |
|---|---|
| Түбәне төзекләндерү | 22131520,22 |
| Йорт эчендәге инженерлык системаларын төзекләндерү, шул исәптән: | 24092525,90 |
| Электр белән тәэмин итү | 3326805,55 |
| Җылылык белән тәэмин итү | 12702886,26 |
| Су белән тәэмин итү | 3101616,82 |
| Суны агызып җибәрү | 4961217,27 |
| Фасадларны җылыту һәм төзекләндерү | 9163537,77 |
| Күпфатирлы йортларда подъездларны төзекләндерү | 1374305,11 |
| Проект документациясен эшләү һәм дәүләт экспертизасы үткәрү | 1408080,94 |
| Төзелеш контроле уздыру | 567618,54 |
| Техник паспортларны ясау | 196735,20 |
| БАРЛЫГЫ | 58934323,68 |

2019 елда күпфатирлы йортларда капиталь ремонт эшләренең финанс чыганаклары ихтыяҗлары күләме

| Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь төзекләндерү буенча хезмәтләр яки эшләрнең исемлеге | Финанслау ихтыяҗы, сумнарда |
|---|---|
| Түбәне төзекләндерү | 17444594,20 |
| Йорт эчендәге инженерлык системаларын төзекләндерү, шул исәптән: | 27482728,85 |
| Электр белән тәэмин итү | 3187778,11 |
| Җылылык белән тәэмин итү | 15348449,92 |
| Су белән тәэмин итү | 3346255,70 |
| Суны агызып җибәрү | 5600245,12 |
| Фасадларны җылыту һәм төзекләндерү | 5328043,00 |
| Күпфатирлы йортларда подъездларны төзекләндерү | 4386764,00 |
| Проект документациясен эшләү һәм дәүләт экспертизасы үткәрү | 1639263,90 |
| Төзелеш контроле уздыру | 546421,30 |
| Техник паспортларны ясау | 302050,5 |
| БАРЛЫГЫ | 57129865,75 |

## V. Капиталь ремонт буенча эшләр һәм хезмәтләрнең бәясе

2017-2019 елларга торакның гомуми мәйданының 1 кв. м исәпләгәндә күп фатирлы йортларда капиталь ремонт эшләре һәм хезмәт күрсәтү күләме бәясе 14 мең сум тәшкил итә.

Эшләнгән эшләр бәясе бу бәядән артып китү очрагында, шулай ук Кыска вакытлы план буенча каралмаган хезмәтләргә түләү торак хуҗаларының төзекләндерүгә җыелган минималь кертемнәреннән тыш өстәмә җыелган акчалардан башкарыла.

## VI. Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру тәртибе

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты:

Федераль закон нигезендә финанс ярдәме күрсәтелү шартлары үтәлүен раслаучы документлар һәм Төбәк программасын гамәлгә ашыруның муниципаль кыска вакытлы (еллык ) планнарын формалаштыра һәм Министрлыкка җибәрә;

норматив хокук актларының копияләрен һәм муниципаль берәмлек тарафыннан финанс ярдәме күрсәтелү шартлары үтәлүен раслаучы башка документларны Министрлыкка җибәрә;

капиталь ремонт үткәрү өчен подрядчы оешма сайлауда катнаша;

КС-2 формасы буенча башкарылган эш актларын килештерә;

торак законнары нигезендә, әлеге кыска вакытлы план белән билгеләнгән күләмдә, Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә җирле бюджеттан капиталь ремонт эшләрен уртак финанслау максатыннан акча күчерә;

күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау эшләрендә расланган сметада каралмаган чыганакларны куллану очракларыннан тыш һәм артык чыгымнар булган очракта, капиталь ремонт эшләрен кабул итү актын килештерә;

күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау эшләренә бүленеп бирелә торган акчаның максатчан файдалануны гамәлгә ашыруны тикшерүдә тота;

Министрлык тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, тиешле муниципаль берәмлек буенча, кыска вакытлы планны тормышка ашыру максатларында, мәгълүматлар базасын булдыра һәм актуаль хәлдә алып бара;

төзелеш Фондына хисап өчен кирәкле документлар һәм белешмәләрне Министрлыкка тапшыра.

ТМШ(ТСЖ), ТК (ЖК), ТТК (ЖСК), идарә итү оешмалары:

капиталь ремонт уздыру өчен тикшерү актларын, төзәтеләсе кимчелекләр исемлеген килештерәләр;

дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алуны да кертеп, проект документациясен хәзерләүне тәэмин итәләр;

Министырлык тарафыннан расланган тәртип нигезендә сайлап алуны оештыручылар булып катнашалар;

капиталь төзекләндерүне башкару өчен подрядчы оешмалар сайлау өлешендә катнашалар;

объектларга капиталь ремонт уздыру өчен шартлар тудыру мөмкинлеген тәэмин итәләр;

күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлауны вакытында һәм сыйфатлы итеп башкаруны, шулай ук капиталь ремонт тәмамланган объектларны файдалануга тапшыру актларын, тикшерү актларын имзалау аларны кулланылышка кертүне контрольдә тотуда катнашалар.

Торак хуҗалары:

капиталь ремонт уздыру өчен тикшерү актларын, төзәтеләсе кимчелекләр исемлеген килештерәләр;

күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлауны вакытында һәм сыйфатлы итеп башкаруны, шулай ук капиталь ремонт тәмамланган объектларны файдалануга тапшыру актларын, тикшерү актларын имзалау аларны кулланылышка кертүне контрольдә тотуда катнашалар;

Подрядчы оешмалар:

күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлауны вакытында, подряд килешүе нигезендә башкаруны тәэмин итәләр;

КС-2, КС-3 формасы буенча эшләнгән эшләрнең актларын тутыралар;

подряд килешүе нигезендә каралган башка эш төрләрен башкаралар.

“Татмедиа” ААҖ филиалы “Дуслык” (“Дружба», «Туслах») газетасы Кыска вакытлы план чараларының үтәлешен матбугат битләрендә даими яктырта.

Кыска вакытлы планны мониторинглау, гамәлгә ашыру һәм үтәлешен контрольдә тоту, планлаштыру “Торак фонды мониторингы” бердәм мәгълүмат системасында башкарыла.